Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Пыжмара авылы

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март 2024 ел. №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Пыжмара торак пунктында узган халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Пыжмара торак пунктында узган гражданнар җыелышында 2023 елның 18 ноябрендә кабул ителгән 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

- төзәтү, коймалар тоту, традицион күмү урыннарын төзекләндерү: Пыжмар авылы зираты коймасын төзәтү өчен материаллар сатып алу һәм Пыжмара авылы зираты коймасын төзәтү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү: янгынга каршы колонкаларга тулыландыручы әсбаплар һәм мотопомпа сатып алу.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев